**Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы Норма авыл җирлегенең Кариле авылы торак пунктында**
**ХАЛЫК ҖЫЕНЫ КАРАРЫ**

**16 декабрь 2021 ел** **№2**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьяларына, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясына карата, Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы Норма авыл җирлегенең Кариле авылы торак пунктында халык җыены **карар бирде**:

1. 100 % күләмендә ташлама каралган I нче төркем инвалидларын, тыл хезмәтчәннәрен, 80 яшьтән узган өлкәннәрне, ялгыз яшәүче, балалары булмаган 70 яшьтән узган әлкәннәрне исәпкә алмаганда, Балтач муниципаль районы Норма авыл җирлегенең Кариле авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган гражданнарга 2022 нче елда үзарасалымны 700 сум күләмендә кертергә.

2. Алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияткә ия булган мәсьәләләрне хәл итүгә җибәрергә:

- юл-урам челтәрен һәм асфальт-бетон катламын норматив хәлгә китерү;
- Тынычлык һәм Г.Ашрафзянов урамнарындагы балалар мәйданчыклары өчен коймалар сатып алу һәм урнаштыру;
- агач кисү;
- Г.Ашрафзянов 9 нчы һәм 15 нче йотларның коймаларын төзекләндерү.

3. Халык җыены нәтиҗәләрен Норма авыл җирлеге Советының мәгълүмәти стендларында урнаштырырга, http://pravo.tatarstan.ru Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмәт рәсми порталында, Татарстан Республикасы мунципаль берәмлекләре порталы составындагы Балтач муниципаль районы сайтында бастыру юлы белән халыкка җиткерергә.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү өчен җибәрергә.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Муниципаль берәмлек башлыгы,
Совет Рәисе Шарипҗанов Р.Н.